КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 апрель г.Казань № 287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмә-ләрен финанслашу өчен Татарстан Респуб-ликасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка

бюджетара тран-сфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 ноябрь, 1032 нче, 2020 ел, 25 декабрь, 1189 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Респуб-ликасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башка бюджетара трансфертлар җирле үзидарә органнарының төзелеш, реконструкцияләү, техник яжадан җиһазлау, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне (шул исәптән су белән тәэмин итүне оештыру максатларында җиһазлар сатып алу өлешендә), су чыгаруны оештыру, социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын тоту, капиталь ремонтлау һәм сүтү; социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерү һәм ремонтлау; тышкы төзекләндерү объектларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән авария хәлендәге торак йортларны җимерүне гамәлгә ашыру өлешендә; проект һәм эзләнү эшләрен башкару өлешендә проектларны гамәлгә ашыру; күпфатирлы йортларда урнашкан торак булмаган биналарга базар бәяләрен үткәрү; коммуналь техника сатып алу һәм ремонтлау, Авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын гамәлгә ашыру кысаларында билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урыннар арендалау, күпфатирлы йортларда авария хәлендәге һәлакәтләргә бәйсез экспертиза уздыру чараларын (алга таба - төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чаралар) гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында бирелә.»;

7 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, техник җиһазландыруга, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны оештыруга, социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерүгә һәм ремонтлауга карата – расланган проект документациясе нигезендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү, техник җиһазландыру, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны оештыру, социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерү һәм ремонтлау барышында кулланыла торган төзелеш материаллары һәм эшләр башкару ;

су белән тәэмин итүне оештыру максатларында җиһазлар сатып алуга карата - төзелгән шартнамәләр нигезендә;»;

9 пунктның «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«су белән тәэмин итүне оештыру максатларында җиһазлар сатып алуга карата түбәндәге формула буенча:

$$P_i = \sum N_o \times S_o,$$

монда:

$NN_k$ *M*kNNkko - сатып алына торган җиһазларның о тибындагы төре;

$S_o$ - сатып алына торган җиһазларның о-нчы тибы бәясе, ул коммерция бәяләре мониторингы нәтиҗәләре буенча тәкъдимнең иң түбән бәясе буларак билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин